**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисабы» дәүләт мәгълүмат системасы турында

Финанслар һәм бюджет даирәсендә дәүләт идарәсе нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең эшчәнлегенә бухгалтерлык исәбе алып барганда, бухгалтерлык хисабы төзегәндә, хезмәт хакы исәпләгәндә һәм физик затларга башка түләүләрне башкарганда мәгълүмати технологияләр кертү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисабы» дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы заказчысын билгеләргә;

60 көн вакыт эчендә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга һәм аны куллануга кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын эшләтү һәм үстерү эшләрен, шул исәптән андагы мәгълүматны саклауны тәэмин итү эшләрен дә, финанслауны ел саен күздә тотарга;

әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

бухгалтерлык исәбе алып барганда, бухгалтерлык хисабы төзегәндә, хезмәт хакы исәпләгәндә һәм физик затларга башка түләүләрне башкарганда Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә таянып файдаланырга;

үз карамакларындагы учреждениеләрнең Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән вакыт эчендә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын куллануларын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органы булмаган дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм алар карамагындагы учреждениеләргә бухгалтерлык исәбе алып барганда, бухгалтерлык хисабы төзегәндә, хезмәт хакы исәпләгәндә һәм физик затларга башка түләүләрне башкарганда Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын куллануны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 24 май
№ ПУ-295